# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Якты-Күл авылында 2021 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**31.10.2020ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Учук» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);
- Якты Күл авылында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру);
- Якты Күл авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту: (Якты-Күл урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Якты Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре);
- Якты Күл авылы зиратында контейнер мәйданчыкларын төзү (контейнер, киртә өчен материаллар сатып алу, коймалар әзерләү һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары төзү (нигез, коймаларны урнаштыру);
- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт, Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:// pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина